**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Тимерлек авыл җирлеге Чуаш Тимерлеге авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ**

«25» октябрь 2024 ел № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Тимерлек авыл җирлеге Чуаш Тимерлеге авылы гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Тимерлек авыл җирлегенең Чуаш Тимерлеге авылы территориясендә теркәлгән Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларның тол калган хатыннарыннан, 1 группа инвалидлардан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан кала балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Тимерлек авыл җирлеге Чуаш Тимерлеге авылы торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту»

Халык җыенында рәислек итүче: В.И. Гаврилов

Тимерлек авыл җирлеге башлыгы В.И. Гаврилов